**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Балтач авыл җирлеге Советы**
**Карары**

**2018 ел, 25 сентябрь** **№ 78**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында”гы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында”гы Татарстан Республикасы Законының 18 маддәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы “Балтач авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 15 маддәсе, 2018 елның 11 сентябрендәге “Җирле референдум үткәрү инициативасы турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетының 5нче номерлы карары, 2018 елның 11 сентябрендәге “Җирле референдум үткәрү инициативасы турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 77нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы “Балтач авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы “Балтач авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2019 елда 500 сум үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

*** Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Мәктәп урамы, Кооператив урамы, Үзәк урамы буенча юлларны ремонтлау

* **Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- торак пункт эчендә чүп үләннәре чабу (җәйге-көзге чор)

- Кооператив урамы буенча чишмәләрне ремонтлау.

* **Җирлек халкын су белән тәэмин итүне оештыру:**

- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау (скважиналарның санитар-яклагыч зоналарын киртәләү, чыгым материаллары сатып алу)

* **Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**

- Мәктәп урамы, Үзәк урамы буенча янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балтач авылы, Мәктәп ур., 1нче йорт, Балтач авыл җирлеге;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балтач авылы, Мәктәп ур., 2нче йорт, Балтач авылы мәдәният йорты, шулай ук “Волжские зори” (“Идел таннары”) газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Балтач авыл җирлеге Башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Балтач авыл җирлеге
Советы рәисе Д.И. Мухамадуллин